**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮГАРЫ АКХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

14 февраль, 2023 ел № 83

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының "Әлмәндәр авыл җирлеге"муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында " 29.12.2022 ел, №612-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Акхуҗа авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Акхуҗа авыл җирлеге Советының 2018 елның 1 августындагы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы «Югары Акхуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә турында» гы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Акхуҗа авыл җирлеге Советының 65 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяның бишенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.
3.Әлеге карар 2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә.
4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Акхуҗа җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Югары Акхуҗа авыл**
**җирлеге башлыгы** **З.Я.Юзеев**